ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.11.2015 г.Казань № 151

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының ведомство
бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 22 статьясы, 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 апрелендәге “Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре” 234 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында эшләүчеләрне хезмәт (эш) эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен, шулай ук бүтән оешмаларда (учреждениеләрдә) эшләүчеләрне һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларны хәл итүдә теләктәшлек күрсәтүче затларны туризм һәм туристлык индустриясе өлкәсендәге күренекле казанышлары өчен бүләкләү системасын камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының түбәндәге ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасы турында нигезләмә (1 кушымта);

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты турында нигезләмә (2 кушымта);

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының ведомство бүләгенә тәкъдимнамә рәвеше (3 кушымта);

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының ведомство бүләкләре белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу дәфтәренең рәвеше (4 кушымта).

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
26.11.2015,
№ 151 боерыгына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының
Мактау грамотасы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Мактау грамотасы турында нигезләмә (алга таба – Мактау грамотасы) Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) ведомство бүләге булып санала.

Мактау грамотасы белән Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре), Дәүләт комитетында эшләүчеләр, шулай ук бүтән оешмаларда (учреждениеләрдә) эшләүчеләр һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларны хәл итүдә теләктәшлек күрсәтүче затлар туризм һәм туристлык индустриясе өлкәсендәге күренекле казанышлары өчен бүләкләнә.

2. Дәүләт хезмәткәрләре һәм Дәүләт комитетында эшләүчеләр вазифаи бурычларын үрнәк булырлык итеп башкарган һәм тел тидермәслек эше өчен, эш стажы кимендә 5 ел булганда, һәм элегрәк Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән очракта, бу бүләкләүдән соң кимендә 1 ел узгач Мактау грамотасы белән бүләкләнәләр.

Дәүләт хезмәткәренең һәм Дәүләт комитетында эшләүченең 50, 55, 60, 65 яшьлек һәм аннан соңгы юбилей даталарына ирешүе аларга Мактау грамотасы бирү өчен мөстәкыйль нигез булып тора.

3. Оешмаларның (учреждениеләрнең) коллективларын Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен 20 еллык һәм аннан соң һәр 5 елдан соңгы юбилей даталары билгеләнә.

4. Мактау грамотасы белән бүләкләү карары Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кабул ителә.

5. Мактау грамотасы белән бүләкләү Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә Дәүләт комитеты рәисе урынбасарының, Дәүләт комитетындагы структур бүлекчәләрдәге җитәкчеләренең язмача үтенечнамәсе, шулай ук Дәүләт комитеты рәисе инициативасы нигезендә башкарыла.

Бүтән министрлыкларның, ведомстволарның һәм оешмаларның дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм (яки) аларда эшләүчеләргә карата бүләкләү материаллары шулай ук әлеге министрлыкларның, ведомстволарның һәм

оешмаларның җитәкчеләренең язмача үтенечнамәсе, шулай ук Дәүләт комитеты рәисенең инициативасы нигезендә карап тикшерелә.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә, шушы Боерыкның 3 кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының ведомство бүләге белән бүләкләнүгә карата тәкъдимнамә теркәлергә тиеш.

7. Дәүләт комитеты игълан иткән республика конкурсларында җиңүчеләр конкурс нәтиҗәләре буенча тиешле конкурс комиссиясенең тәкъдимнамәсе нигезендә Мактау грамотасы белән бүләкләнә ала.

8. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә карата материаллар Дәүләт комитеты рәисенә тиешле датага кадәр ике айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

9. Шушы Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне бозып, Дәүләт комитетына тапшырылган Мактау грамотасы белән бүләкләүгә карата материаллар аларны тапшыручы затларга кире кайтарып бирелә.

10. Ел дәвамында дисциплинар шелтәләр алган затлар Мактау грамотасы белән бүләкләнергә тиеш түгел.

11. Мактау грамотасын тапшыру, кагыйдә буларак, тантаналы шартларда Дәүләт комитеты рәисе яки аның кушуы буенча бүтән вазифаи затлар тарафыннан бүләкләнә торган зат эшләүче коллективта тапшырыла.

12. Дәүләт комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрнең хезмәт кенәгәсенә тиешле язу теркәлә.

13. Дәүләт комитетының Рәхмәт хатыннан гайре, дәүләт яки ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затлар алдагы бүләкләүдән соң кимендә өч ел узгач Мактаулы грамота белән бүләкләүгә тәкъдим ителә ала.

14. Мактау грамотасы югалган очракта аның дубликаты бирелми. Дәүләт комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы боерыгының күчермәсе Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан бирелә.

15. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән затлар, оешмаларның (учреждениеләрнең) коллективлары Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының ведомство бүләге белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу дәфтәрендә (4 кушымта) исәпкә алына һәм теркәлә.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
26.11.2015,
№ 151 боерыгына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының
Рәхмәт хаты турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык вазифаларын биләүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре), Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) эшләүчеләрне тармакны үткәрүдәге билгеле бер әһәмиятле шәхси өлеше өчен кызыксындыру чарасы булып санала.

2. Дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларны хәл итүдә теләктәшлек күрсәтүче бүтән оешмаларның (учреждениеләрнең) җитәкчеләре, хезмәткәрләре һәм коллективлары һәм затлар Рәхмәт хаты белән бүләкләнергә мөмкин.

3. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турында карар Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кабул ителә.

4. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә, Дәүләт комитеты рәисе урынбасарларының, Дәүләт комитетындагы структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренең язмача үтенечнамәсе, шулай ук Дәүләт комитеты рәисе инициативасы нигезендә башкарыла.

Бүтән министрлыкларның, ведомстволарның һәм оешмаларның дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм (яки) аларда эшләүчеләргә карата бүләкләү материаллары шулай ук әлеге министрлыкларның, ведомстволарның һәм оешмаларның җитәкчеләренең язма үтенечнамәсе, шулай ук Дәүләт комитеты рәисенең инициативасы нигезендә карап тикшерелә.

5. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турындагы үтенечнамәгә, шушы Боерыкның 3 кушымтасына туры китереп, Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә карата тәкъдимнамә теркәлергә тиеш.

6. Дәүләт комитеты игълан иткән республика конкурсларында җиңүчеләр конкурс нәтиҗәләре буенча тиешле конкурс комиссиясенең тәкъдимнамәсе нигезендә Рәхмәт хаты белән бүләкләнә ала.

7. Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә карата материаллар Дәүләт комитеты рәисенә тиешле датага кадәр ике айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

8. Шушы Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне бозып, Дәүләт комитетына тапшырылган Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә карата материаллар аларны тапшыручы затларга кире кайтарып бирелә.

9. Ел дәвамында дисциплинар шелтәләр алган затлар Рәхмәт хаты белән бүләкләнергә тиеш түгел.

10. Рәхмәт хаты Дәүләт комитеты рәисе яки аның кушуы буенча бүтән вазифаи затлар тарафыннан бүләкләнүче эшли торган коллективта тапшырыла.

11. Рәхмәт хаты белән бүләкләнүче Дәүләт комитеты хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә тиешле язу теркәлә.

12. Рәхмәт хаты югалган очракта аның дубликаты бирелми. Дәүләт комитетының Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турындагы боерыгының күчермәсе югалткан очракта Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан бирелә.

13. Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән затлар, оешмаларның (учреждениеләрнең) коллективлары Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш секторы тарафыннан Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының ведомство бүләге белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу дәфтәрендә (4 кушымта) исәпкә алына һәм теркәлә.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
26.11.2015,
№ 151 боерыгына
3 кушымта

Рәвеш

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының
ведомство бүләге белән бүләкләүгә карата
ТӘКЪДИМНАМӘ

______________________________________________________________
(ведомство бүләгенең төре)

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме_________________________________
2. Вазифасы, эш урыны_______________________________________________
_____________________________________________________________________
(структур бүлекчәнең, оешманың, учреждениенең тулы аталашын күрсәтергә)
3. Туган көне________________________________________________________
4. Белеме____________________________________________________________
5. _________________________________________________________тәмамлаган
(белем бирү учреждениесенең аталышы, тәмамлау елы, белгечлеге)
6. Фәнни дәрәҗәсе, фәнни исеме_______________________________________
7. Нинди дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән, датасы______
_____________________________________________________________________
8. Гомуми эш стажы________ Тармактагы эш стажы______________________
__________ Шушы коллективтагы эш стажы_____________________________
9. Хезмәт эшчәнлеге (таблица нигезендә тутырыла)

| Ае һәм елы | | Оешманы күрсәтеп, вазифасы | Оешманың урнашкан урыны |
|---|---|---|---|
| килү | китү | | |
| | | | |

10. Бүләкләнүченең билгеле бер махсус казанышларын күрсәтеп, сыйфатлама:_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________

11.______________кандидатурасы_____________________________________
(оешманың, учреждениенең аталышы)
хезмәт коллективы яки аның советы тарафыннан тәкъдим ителде

_____________________________________________________________________
(фикерләшү датасы, беркетмә №)

Структур бүлекчә, оешма,
Учреждение җитәкчесе ____________________ ______________________
М. у. (инициаллары, фамилиясе) (имзасы)

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча
дәүләт комитетының
26.11.2015,
№ 151 боерыгына
4 кушымта

Рәвеш

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының
ведомство бүләге белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу
дәфтәре

Сул ягы

| № п/п | Структур бүлекчә, оешма, учреждение аталышы | Бүләкләү рәвеше | |
|---|---|---|---|
| | | Дәүләт (Россия Федерациясенең/Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге) | Ведомство (Мактау грамотасы, Рәхмәт хаты) |
| 1. | … | | |

Уң ягы

| Бүләкләнүче | | Бүләкләү турындагы документ | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| Ф.И.А. | Вазифасы | Документ төре | № | Дата (кк.аа.ее.) | |
| | | | | | |

_______________________________________